ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

24 08 2020 г. № 574

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 5 статьясындагы 5 пункты, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары белән, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның кушымта итеп бирелгән административ регламентын расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Житәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 24 нче август
574 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалануга һәм саклауга муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, тикшерүләр оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларын файдалану һәм саклауга муниципаль контроль (алга таба - муниципаль контроль) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Башкарма Комитет вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче орган булып, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – муниципаль контроль органы) тора.

1.3. Муниципаль контроль предметы булып, юридик затларның, аларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм аларның вәкаләтле вәкилләренең федераль законнарда һәм башка норматив хокукый актларда, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәү тора (алга таба - мәҗбүри таләпләр).

1.4. Муниципаль контроль түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 2395-1 номерлы закон) («РФ законнары җыелмасы», 06.03.1995, № 10, 823 ст.);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) («РФ законнары җыелмасы», 29.12.2008, № 52 (1 ө.), 6249 ст.);

- «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм файдалы казылма төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану белән бәйле эшләр башкаруга башка проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы РФ Хөкүмәте карары (алга таба – 118 номерлы РФ Хөкүмәте карары) («РФ законнары җыелмасы», 08.03.2010, № 10, 1100 ст.);

- «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы РФ Хөкүмәте карары (алга таба – 489 номерлы РФ Хөкүмәте карары) («РФ законнары җыелмасы», 12.07.2010, № 28, 3706 ст.);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җир асты су объектларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 11 февралендәге 94 номерлы карары (алга таба – 94 номерлы РФ Хөкүмәте карары) («РФ законнары җыелмасы», 22.02.2016, № 8, 1115 ст.);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Россия Икътисад министрлыгының 141 номерлы боерыгы) («Российская газета», № 85, 14.05.2009);

- «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», № 14, 22.01.2000);

- «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы», 14.12.2011, № 47, 2507 ст.);

- «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау

тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары (алга таба – 275 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы», 24.05.2013, № 38);

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген раслау турында» 2014 елның 15 сентябрендәге 637-п номерлы боерыгы (алга таба - 637-п номерлы боерык);

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2015 елның 24 маендагы 7 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитетның 2015 елның 29 декабрендәге 1323 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ турында нигезләмә (алга таба – Идарә турында Нигезләмә).

1.5. Муниципаль контроль, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең гомуми таралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Контроль буенча чаралар планлы яки планнан тыш тикшерүләр рәвешендә үткәрелә. Планлы яки планнан тыш тикшерүләр документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

1.6. Тикшерүләр уздырганда, муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктында, 18 статьясында каралган йөкләмәләрне үтәргә, шулай ук 294-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган чикләүләрне үтәргә тиеш. Тикшерү барышында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокуклары 294-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән.

1.7. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан, федераль законнарда һәм башка норматив хокукый актларда, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозу фактын (фактның булмавын) ачыклау тора.

## 2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр

2.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында хәбәр итү тәртибе.

2.1.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм барышы турында мәгълүмат алу өчен кызыксынган затлар муниципаль контроль органына

мөрәҗәгать итә.

Муниципаль контроль органынының урнашу урыны: Түбән Кама шәһәре, Мәктәп бульвары, 2А йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе - җомга: 8:00 - 17:00;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон: 8(8555)47-32-42.

Керү ирекле.

2.1.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтының адресы (алга таба - «Интернет» челтәре): (http://www.e-nkama.ru).

2.1.3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында, шулай ук муниципаль контроль органының урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) кызыксынган затлар белән эшләү өчен муниципаль контроль органы биналарында урнашкан муниципаль контроль турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат туплаган мәгълүмати стендлар аша;

2) «Интернет» челтәре аша Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru);

3) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

4) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

5) муниципаль контроль органында:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша;

2.1.4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында һәм кызыксынган затлар белән эшләү өчен муниципаль контроль органы биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

2.2. Муниципаль контроль буенча чаралар үткәргән өчен, шул исәптән тикшерүләр үткәрүгә җәлеп ителгән очракта, эксперт һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән түләү алынмый.

2.3. Документар һәм күчмә тикшерүләр үткәрү вакыты аларның һәркайсы өчен 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш. Кече эшмәкәрлек субъектына тикшерү уздырганда, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерүне уздыру муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан ведомствоара мәгълүмати бәйләнешне

гамәлгә ашыру өчен кирәкле, әмма 10 эш көненнән дә артмаган срокта туктатылып торырга мөмкин. Тикшерүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Планлы күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә, катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарурлыгына бәйле аерым очракларда, күчмә планлы тикшерүне үткәрү вакыты мондый орган җитәкчесе тарафыннан 20 эш көненнән артык булмаган срокка, кече предприятиеләргә карата илле сәгатьтән дә артык түгел, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән дә артык түгел срокка озайтылырга мөмкин.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы юридик затка карата документар һәм күчмә тикшерүләр үткәрү вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерым структур бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерүне үткәрүнең гомуми вакыты аларның һәркайсы өчен 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Планлы тикшерүләр, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 9 һәм 9.3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, өч елга бер тапкырдан да артык үткәрелми.

2.4. Тикшерүләр Россия Икътисад министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган типлаштырылган форма нигезендә әзерләнгән муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә.

2.5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге:

1) «ТР Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ башлыгы;

2) «ТР Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары:

3) «ТР Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ җир контроле бүлеге башлыгы;

4) «ТР Түбән Кама муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе» МКУ җир контроле бүлегенең әйдәп баручы белгече.

2.6. Тикшерүләр уздырганда, юридик затлар җитәкчеләр, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре катнашуны тәэмин итәргә тиеш, шәхси эшмәкәрләр катнашырга тиеш яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә тиеш.

294-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаучы, тикшерүләр үткәрүдән качып йөрүче һәм (яисә) муниципаль контроль органнарының муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрен билгеләнгән вакытка үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

2.7. Муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү уздырганда, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законнары

нигезендә җаваплы.

Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларның хезмәт йөкләмәләрен үтәвен контрольдә тота, вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаеплеләргә карата кабул ителгән чаралар турында муниципаль контроль органы, мондый чаралар күргән көннән 10 көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куелган мәҗбүри таләпләр. Тикшерүләр үткәргәндә, юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырыла торган документлар

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр, әлеге таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар, шулай ук, тикшерү үткәргәндә, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

3.1. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр, шулай ук, тикшерү үткәргәндә, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документлар каралган:

1. «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы

2. «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм файдалы казылма төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану белән бәйле эшләр башкаруга башка проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы РФ Хөкүмәте карары;

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җир асты су объектларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 11 февралендәге 94 номерлы карары;

4. «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары.

## 4. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

4.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

а) юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерү үткәрү һәм үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү;

б) юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү һәм үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү;

в) документар тикшерү үткәрү;

г) күчмә тикшерү үткәрү;

д) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

е) тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү.

4.1.2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында тәкъдим ителгән.

4.2. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы тикшерү үткәрү һәм үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү.

4.2.1. Планлы тикшерүләр муниципаль контроль органнары тарафыннан аларның вәкаләтләре нигезендә эшләнә һәм раслана торган планнар нигезендә үткәрелә. Еллык планның типлаштырылган формасы һәм аны әзерләүгә карата таләпләр РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары белән каралган.

4.2.2. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына планлы тикшерүне кертү өчен 294-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 8 өлешендә каралган очраклар нигез булып тора.

4.2.3. Әлеге Регламентның 4.2.1 пунктында каралган нигез булса, юридик затка яки шәхси эшмәкәргә карата планлы тикшерү үткәрү турында күрсәтмә проектын әзерләүгә вәкаләтле муниципаль контроль органының вазыйфаи заты күрсәтелгән күрсәтмә проектын әзерләүне гамәлгә ашыра. Планлы тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмә проекты тикшерү башланган көнгә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча имзага кертелә һәм имзага кертелгәннән соң 3 көн эчендә муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан имзалана.

4.2.4. Планлы тикшерү үткәрүнең башлануы турында муниципаль контроль органы күрсәтмәсенең күчермәсе юридик затка, шәхси эшмәкәргә муниципаль контроль органы тарафыннан аны үткәрә башлаганчы, өч эш көненнән дә соңга калмыйча, заказлы почта аша, тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ рәвешендә җибәрелә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элек юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан муниципаль контроль органына тәкъдим ителгән булса яки башка үтемле ысул белән.

4.3. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү һәм үткәрүгә әзерлек турында карар кабул итү.

4.3.1. Планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә каралган очраклар нигез булып тора.

4.3.2. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2.1 пунктында, 2 пунктның «а», «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң, муниципаль контроль органнары тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

4.3.3. Юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очракларын бетерү турындагы күрсәтмәнең үтәлү срогы чыгу

планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булган очракта, мондый тикшерү предметы булып, бары тик муниципаль контроль органы биргән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.

4.3.4. Мәҗбүри таләпләрне, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торган фактлар турында тиешле мәгълүматларны бозуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат булмаганда, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматны алдан тикшерү үткәрелергә мөмкин.

Кергән мәгълүматка алдан тикшерү уздыру барышында, мәгълүмат тапшырган, гариза һәм мөрәҗәгать җибәргән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик зат, шәхси эшмәкәрнең муниципаль контроль органы карамагында булган документларын карау үткәрелә, кирәк булганда, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешкә кермичә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүмат бирү һәм муниципаль контроль органнары таләпләрен үтәү буенча вазыйфалар йөкләмичә генә контрольдә тоту буенча чаралар үткәрелә. Алдан тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратып алынырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны тапшыру мәҗбүри түгел.

Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торган фактлар турында тиешле мәгълүматларны алгач, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган затларны алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыклагач, муниципаль контроль органының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында дәлилләнгән күрсәтмә әзерли. Алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

4.3.5. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булган очракта, планнан тыш тикшерү үткәрү турында күрсәтмә проектын әзерләүгә вәкаләтле муниципаль контроль органының вазыйфаи заты күрсәтмә проектын әзерләүне гамәлгә ашыра. Планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмә проекты тикшерү башланган көнгә кадәр 4 көннән дә соңга калмыйча әзерләнә һәм аны әзерләгән көннән алып 1 эш көне эчендә муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан имзалана.

294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2.1 пунктында, 2 пунктның «а», «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү очрагында, вазыйфаи зат планнан тыш тикшерү үткәрү турында күрсәтмә проектын әзерләү белән бер үк вакытта, планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүне прокуратура органнары белән килештерү турында гариза проектын (алга таба – килештерү турында гариза) әзерләүне гамәлгә ашыра. Муниципаль контроль органы тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү тәртибе Россия Генпрокуратурасының 93 номерлы боерыгы белән каралган.

4.3.6. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында, аны үткәрү нигезләре 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш, юридик затка, шәхси эшмәкәргә

муниципаль контроль органы аны үткәрү башланганчыга кадәр егерме дүрт сәгать алдан теләсә нинди мөмкин булган алым белән хәбәр итә, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы буенча җибәрелгән электрон документ аша, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса яки элек юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан муниципаль контроль органына тәкъдим ителгән булса.

4.3.7. Муниципаль контроль органы җитәкчесе карары буенча планнан тыш тикшерү, алдан тикшерү, тиешле тикшерү башланганнан соң, аны оештыруга сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада күрәләтә ялган мәгълүмат булуы ачыкланса туктатыла.

4.4. Документар тикшерү үткәрү.

4.4.1. Документар тикшерү предметы булып, юридик зат, шәхси эшмәкәр документларындагы аларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган белешмәләр, аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль контроль органнары күрсәтмәләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле документлар тора.

4.4.2. Документар тикшерү муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә һәм муниципаль контроль органы урнашкан урында үткәрелә.

Тикшерү бары тик муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсендә күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

4.4.3. Муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсенең мөһере белән таныкланган күчермәләре муниципаль контроль органының тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан, имза куйдырып, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә хезмәт таныклыкларын күрсәтү белән бер үк вакытта тапшырыла.

Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары әлеге органнар турында, шулай ук үз вәкаләтләрен раслау максатларында экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент белән таныштырырга тиеш.

4.4.4. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан документар тикшерү уздыру барышында, беренче чиратта юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль контроль органы карамагында булган документлары карала.

4.4.5. Муниципаль контроль органы карамагында булган документларындагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса яисә бу мәгълүматлар юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми икән, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тикшерү

субъектына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән нигезләнгән сорату проектын әзерли (алга таба - сорату) һәм аны муниципаль контроль органы җитәкчесенә имзалауга тапшыра.

Муниципаль контроль органы җитәкчесе имзалаган сорату, муниципаль контроль органы җитәкчесенең тикшерү үткәрү турындагы мөһер белән таныкланган күчермәсен кушып, тикшерү субъекты яисә аның вәкиленә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша җибәрелә, шулай ук факсимиль элемтә яки электрон почта аша кабатлана.

4.4.6. Дәлилләнгән сорату алынганнан соң 10 эш көне эчендә юридик зат, шәхси эшмәкәр соратуда күрсәтелгән документларны мөһер белән (булганда) таныкланган күчермәләр рәвешендә һәм шуңа бәйле рәвештә шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, юридик затның бүтән вазыйфаи заты имзасы белән муниципаль контроль органына җибәрергә тиеш. Юридик зат, шәхси эшмәкәр соратуда күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

4.4.7. Документар тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр тапшырган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган яки бу документлардагы белешмәләрнең муниципаль контроль органында булган документларда һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланган очракта, бу хакта юридик затка, шәхси эшмәкәргә 10 эш көне эчендә язма рәвештә тиешле аңлатмалар бирү таләбе белән мәгълүмат җибәрелә.

4.4.8. Муниципаль контроль органына тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга яисә әлеге Регламентның 4.4.8 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик зат, шәхси эшмәкәр элек бирелгән документларның дөреслеген раслый торган документларны өстәмә рәвештә муниципаль контроль органына тапшырырга хокуклы.

Документар тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, җитәкче яисә юридик затның бүтән вазыйфаи заты, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан элек бирелгән документларның дөреслеген раслый торган тапшырылган аңлатмаларны һәм документларны карарга бурычлы.

4.4.9. Бирелгән аңлатмаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаганда, муниципаль контроль органы мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы. Күчмә тикшерүне уздырганда, юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документар тикшерү үткәрү барышында тапшырылган документлар һәм (яки) мәгълүматны таләп итү тыела.

4.5. Күчмә тикшерү үткәрү.

4.5.1. Күчмә тикшерү предметы булып, юридик зат, шәхси эшмәкәр документларындагы белешмәләр, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларыннан файдалану буенча

эшчәнлекне тормышка ашырганда, мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча алар тарафыннан күрелә торган чаралар тора.

4.5.2. Күчмә тикшерү муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә һәм юридик затның урнашу урыны, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек алып бару урыны һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

Тикшерү бары тик муниципаль контроль органы җитәкчесе күрсәтмәсендә күрсәтелгән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи затлар тарафыннан гына үткәрелергә мөмкин.

4.5.3. Күчмә тикшерү документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә булган белешмәләрнең һәм муниципаль контроль органы карамагындагы бүтән документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп белергә;

2) юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең контроль буенча тиешле чара үткәрмичә генә мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләргә.

4.5.4. Тикшерү уздыру урынына килүгә, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты:

- тикшерү субъектына яки аның вәкиленә хезмәт таныклыгын күрсәтә;

- юридик затның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен түбәндәгеләр белән таныштырырга тиеш:

муниципаль контроль органы җитәкчесенең күчмә тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе;

күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре;

күчмә тикшерүне үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре;

контроль буенча чаралар төрләре һәм күләме;

экспертлар составы, күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре;

күчмә тикшерү уздыру вакыты һәм шартлары.

Тикшерелергә тиешле затлар таләбе буенча муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары әлеге органнар турында, шулай ук үз вәкаләтләрен раслау максатларында экспертлар, эксперт оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны әлеге Регламент белән таныштырырга тиеш.

4.5.5. Муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тикшерү субъекты яки аның вәкиле белән берлектә тикшерү барышында үзара хезмәттәшлек итәчәк затлар даирәсен билгели, тикшерү субъекты яки аның вәкиле танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиешле документлар исемлеген аныклый, шулай ук вакытлы тикшерү режимын (тикшерү субъектының гамәлдәге эш режимын исәпкә алып).

4.5.6. Тикшерү барышында гамәлгә ашырыла:

а) җир кишәрлеген, җир асты байлыклары участогын тикшерү;

б) фото -, видео төшерү, инструменталь төшерү;

в) документларны һәм тапшырылган мәгълүматны анализлау;

г) 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган контроль буенча кирәкле тикшерүләр, экспертизалар һәм башка чаралар үткәрү.

4.5.7. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи затларына, күчмә тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән очракта, күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметлары белән бәйле документлар белән танышу мөмкинлеге бирергә, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның һәм күчмә тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең территориягә, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлекне гамәлгә ашырганда файдалана торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кулланыла торган җиһазларга, мондый объектларга керүен тәэмин итәргә тиеш.

4.5.8. Тикшерү субъекты тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлеген, җир асты байлыклары участогын тикшерү, тикшерү субъекты яки аның вәкиле булганда, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла. Җир кишәрлеген, җир асты участогын тикшерү барышында, мәҗбүри таләпләрне бозу фактларын ачыклаганда, алар фото -, видео -, инструменталь төшерү аша теркәлә, бу хакта тикшерү субъектына яки аның вәкиленә телдән хәбәр ителә. Соңыннан мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары тикшерү актында чагыла.

4.5.9. Документлар (мәгълүмат) һәм (яки) аларны тапшыруга комачаулаучы башка шартлар булган очракта, тикшерү субъекты муниципаль контроль органы вазыйфаи затына документларны тапшырмау сәбәпләрен язмача аңлатуны бирергә хокуклы.

4.5.10. Тикшерү субъекты тикшерү үткәрү өчен кирәкле документларны тапшырудан баш тарткан очракта, тикшерү актында тиешле язма башкарыла.

4.5.11. Планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче яки юридик затның бүтән вазыйфаи заты булмау сәбәпле яисә юридик зат, шәхси эшмәкәрнең фактта эшчәнлеген башкармауга бәйле рәвештә яисә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, җитәкченең яисә юридик затның бүтән вазыйфаи затының бүтән гамәлләре (гамәл кылмавы) белән бәйле рәвештә, тикшерү мөмкин булмаган очракта, муниципаль контроль органының вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкин булмауның сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмавы турында акт төзи.

Бу очракта муниципаль контроль органы, тиешле тикшерү уздыру мөмкинлеге булмау турындагы акт төзелгәннән соң өч ай эчендә, планлы тикшерүләрнең еллык планына планлы тикшерүне кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәр итмичә, мондый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

4.6. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

4.6.1. Тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Икътисад министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә акт төзелә.

4.6.2. Тикшерү актына продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын алу беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәләре яки бәяләмәләре, мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән юридик зат, шәхси эшмәкәр хезмәткәрләренең аңлатмалары, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре теркәлә.

4.6.3. Тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарның күчермәләре белән тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында раслама белән тапшырыла.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында расалама бирүдән баш тарткан очракта, акт заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә, ул муниципаль контроль органы делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

Тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә үзара бәйләнешне гамәлгә ашыру ризалыгы булганда, тикшерү акты җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

4.6.4. Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмә алырга кирәк булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң 3 эш көненнән дә артмаган срокта төзелә һәм җитәкчегә, башка вазыйфаи затка, юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә раслама белән тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта белән җибәрелә һәм (яки) әлеге актны төзегән затның (тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон формада үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында күрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта әлеге документны тапшыру турында хәбәрнамә һәм (яки) күрсәтелгән документы алу турында бүтән раслау муниципаль контроль органы делосында саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

4.6.5. 294-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 8 өлеше нигезендә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр алып барырга хокуклы тикшерүне исәпкә алу журналына муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән тикшерү турында язма кертелә, анда муниципаль контроль органы исеме, тикшерү башлану һәм тәмамлану даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләр, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметлары, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр, шулай ук вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, аның яки аларның имзалары күрсәтелә. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язма ясала.

4.6.6. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителгән очракта, тикшерү акты күчермәсе, тикшерү акты төзелгәннән соң 5 эш көне эчендә, тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына җибәрелә.

4.6.7. Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр, тикшерү акты алынганнан соң 15 көн эчендә, тиешле муниципаль контроль органына язмача тикшерү актына һәм (яисә) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә тулаем яки аның аерым нигезләмәләренә каршы килүне тапшырырга хокуклы.

Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр мондый каршы килүгә мондый каршылыкларның нигезлелеген раслый торган документларны яки аларның расланган күчермәләрен яисә килештерелгән вакытта аларны муниципаль контроль органына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелүче затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

4.7. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү.

4.7.1. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозу очракларына карата чаралар күрү өчен нигез булып, тикшерү барышында тикшерү субъекты тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны ачыклау тора.

4.7.2. Тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта, тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә бурычлы:

1) юридик затка, шәхси эшмәкәргә, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында, һәм (яки) гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларына зыян китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында күрсәтмә бирергә. Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә юридик затка, шәхси эшмәкәргә әлеге Регламентның 4.6 пунктында каралган тәртиптә тикшерү акты белән бер үк вакытта бирелә;

2) ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты

корылмаларын төзегәндә, җир асты байлыкларына зыян китерүне булдырмау чараларын, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрергә.

4.7.3. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору яки чикләү турындагы мәсьәләне карау, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган тикшерү субъектын административ җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү максатларында, ачыкланган бозу билгеләре һәм бозуларга күрсәтә торган кушымталарның күчермәләре күрсәтелеп, тикшерү акты төзелгәннән соң 3 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына җибәрелә.

Тикшерү актының күчермәсе муниципаль контроль органы вазыйфаи затының квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә яки электрон документ формасында җибәрү мөмкинлеге булмаган очракта кәгазьдә җибәрелә.

4.7.4. Тикшерү үткәргәндә, аларны үтәү муниципаль контроль орган компетенциясенә керми торган, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне тикшерү субъекты тарафыннан бозуны ачыклаган очракта, муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары күрсәтелгән таләпләрне бозу очракларына күрсәтә торган материаллар әзерлиләр һәм аларны тикшерү акты төзелгәннән соң 5 эш көне эчендә тиешле контроль-күзәтчелек органына озату хаты белән җибәрәләр.

## 5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибе һәм формалары

5.1. Муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

а) агымдагы контроль;

б) муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыруның тулылыгын һәм сыйфатын алга таба тикшереп тору.

5.2. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул итү, әлеге Регламент нигезендә муниципаль контроль функцияләрен үтәү буенча срокларын, гамәлләр эзлеклелеген үтәүне даими контрольдә тотудан торган муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыруга агымдагы контроль муниципаль контроль органы җитәкчесе, муниципаль контроль органы җитәкчесе урынбасары һәм муниципаль контроль органының вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыруга агымдагы контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле муниципаль контроль органы хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм кабатлану вакыты муниципаль контроль органының локаль актлары белән билгеләнә. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга муниципаль контроль органы хезмәткәрләренең вәкаләтләре муниципаль контроль органының структур бүлекчәләре, аның

хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре турындагы нигезләмәләрдә билгеләнә.

5.3. Муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыруның тулылыгына һәм сыйфатына алдагы контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелүче затларның хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, карарлар кабул итү һәм муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләре булган кызыксынган затларның мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Тикшерүләр Башкарма комитет күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерү нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда муниципаль контроль чараларын гамәлгә ашырганда җитешсезлекләр булмау яки ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча планлы тикшерүләр Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән расланган тикшерүләр планы нигезендә, планлы тикшерү өч елга бер тапкырдан да ким үткәрелмәскә тиешлекне исәпкә алып үткәрелә.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча планнан тыш тикшерүләр физик һәм юридик затларның, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләре буенча, шулай ук үткәрелгән тикшерү барышында ачыкланган бозуларны бетерү максатларында, тикшерүләр үткәрүнең расланган планыннан тыш үткәрелә.

5.4. Муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү уздырганда хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмаган) очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Муниципаль контроль органы муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының хезмәт вазыйфаларын башкаруын контрольдә тота, вазыйфаи затларның хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле булган вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында, мондый чаралар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, муниципаль контроль органнары хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

5.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль контроль функциясе үтәлешенә контроль гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, җир асты байлыкларын саклау хокукын тормышка ашыру һәм гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзегәндә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге законнарны бозуны булдырмау максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль контроль үтәлешенә контроль гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан Интернет челтәрендә урнаштырылган

тиешле мәгълүматны кулланып, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм формаларда гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына тапшырылган гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан муниципаль контроль функцияләренең үтәлешен тикшереп тору нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

## 6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

6.1. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә, тикшерү уздырганда юридик зат, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән гамәлләргә (гамәл кылмавына) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

6.2. Муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып, муниципаль функцияне үтәү барышында кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү тора.

6.3. Муниципаль контроль органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән шикаять мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне караудан баш тарту яисә карауны туктату өчен нигезләр каралмаган.

6.4. Шикаятькә җавап бирелми яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча түбәндәге очракларда җавап бирелми:

1) Әгәр язма шикаятьтә юридик затның исеме, шикаять җибәргән шәхси эшмәкәрнең фамилиясе яисә шикаятькә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки эшләнгән хокукка каршы эш турында, шулай ук аны әзерли торган, эшли торган яисә эшләгән зат турында мәгълүмат булса, шикаять аның компетенциясе нигезендә тиешле органга җибәрелергә тиеш);

2) әгәр язма шикаятьтә әдәпсез яисә хурлыклы сүзләр, муниципаль контроль органының вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә куркыныч янау булса, шикаять анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин, күрсәтелгән очракта шикаять җибәргән юридик затка, шәхси эшмәкәргә хокуктан явызларча файдалану ярамаганы турында хәбәр ителә;

3) Әгәр язма шикаять текстын укып булмаса, шикаятькә җавап бирелми, ул муниципаль контроль органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәгәннән соң

7 көн эчендә шикаять җибәргән юридик затка (шәхси эшмәкәргә) хәбәр ителә, әгәр аның исеме (фамилиясе) һәм почта адресын укып булса;

4) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең шикаятендә элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә аның асылы буенча берничә тапкыр язмача җаваплар бирелгән мәсьәлә булса, һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, җитәкче, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, күрсәтелгән шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең бер үк органга яки бер үк вазыйфаи затка җибәрелүе шартында, чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаять җибәргән юридик затка, шәхси эшмәкәргә хәбәр ителә;

5) әгәр шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап дәүләт яки федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматны ачып салудан башка бирелә алмаса, шикаять җибәргән юридик затка (шәхси эшмәкәргә) әлеге мәгълүматларны ачып салу ярамау белән бәйле рәвештә, анда куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә;

6) әгәр язма шикаять тексты аның асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул муниципаль контроль органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәгәннән соң 7 көн эчендә аны җибәргән юридик затка (шәхси эшмәкәргә) хәбәр ителә;

7) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта җавап урнаштырылган мәсьәләне үз эченә алган язмача шикаять кергән очракта, шикаятьне җибәргән юридик затка (шәхси эшмәкәргә), аны теркәгән көннән 7 көн эчендә шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, анда шул ук вакытта суд карарына шикаять белдерелгән шикаять кире кайтарылмый;

8) суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять, теркәлгән көннән алып 7 көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, аны җибәргән юридик затка кире кайтарыла.

6.5. Муниципаль контроль органы, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлап җибәрү өчен күрсәтелгән органга юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән (аларның вәкаләтле вәкиленнән) кергән шикаять, яисә почта аша җибәрү рәвешендә, яисә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланып электрон документ килү нигез булып тора.

6.6. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Башкарма комитетка җибәрелергә мөмкин.

6.7. Башкарма комитетка яисә Башкарма комитетның вазыйфаи затына аларның компетенциясе нигезендә килгән шикаять аны теркәгәннән соң 30 көн эчендә карала.

Аерым очракларда вазыйфаи зат яисә вәкаләтле зат шикаятьне карау срогын 30 көннән дә артмаган вакытка озайтырга хокуклы, шикаять җибәргән юридик затка (индивидуаль эшкуар) аны карау срогын озайту турында хәбәр итә.

6.8. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре булып тора:

1) муниципаль контроль буенча чараларны гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, атап әйткәндә:

а) хезмәт тикшерүе барышында хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

б) хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, мондый чаралар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепләнә торган вазыйфаи затларга карата кабул ителгән чаралар турында язма рәвештә хәбәр итү;

2) муниципаль контроль чараларын гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне, мондый карарның дәлилләнгән нигезе белән юридик затка, шәхси эшмәкәргә язма рәвешендә хәбәр итү юлы белән, канәгатьләндермичә калдыру.

6.9. Башкарма комитетка кергән шикаятькә җавап мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 6.8 пунктында каралган чаралар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә җибәрелә.

Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Административ регламентка
1 нче кушымта

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр, әлеге таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар, шулай ук тикшерү вакытында юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| | Мәҗбүри таләп формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый акт | Тикшерү вакытында юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир асты байлыкларын файдалануга бирү турындагы законнарда билгеләнгән тәртипне үтәү | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 7, 11, 12 статьялары<br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы ТР Законының 24 статьясы | Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә кушымталар (лицензияләнә торган файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары участокларыннан файдаланганда);<br><br>җир кишәрлегенә аренда (милек) шартнамәсе (арендаторлар, милекчеләр өчен);<br><br>җир кишәрлекләрен сәнәгать җирләренә күчерү турында карар күчермәсе (әгәр элек җирләр башка категориягә караган булса);<br><br>тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлек турындагы актының күчермәсе, тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлек штампы белән топографик план; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Җир асты байлыклары участогын бүлеп бирү турында Башкарма комитет карары;<br><br>җир кишәрлегенең кадастр планы |
| 2 | Җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдалану | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 7, 11, 12 статьялары<br><br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы ТР Законының 24 статьясы | Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия<br><br>җир кишәрлегенә аренда (милек) шартнамәсе |
| 3 | Лицензиядә билгеләнгән җир асты байлыклары участокларыннан файдалану шартларын үтәү | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 11 статьясы<br><br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы ТР Законының 21 статьясы | Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә кушымталар (лицензияләнә торган файдалану төрләре буенча җир асты байлыклары участокларыннан файдаланганда); |
| 4 | Җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, эшләрне куркынычсыз алып бару буенча законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәү | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 22 статьясы<br><br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге | Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия, җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә кушымталар;<br>җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга һәм рекультивациягә техник проект |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 1722-XII номерлы ТР Законының 19 статьясы | |
| 5 | Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча планнар һәм чаралар үтәлеше | «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы РФ Законының 22 статья сы<br><br>«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы ТР Законының 19 статьясы | Җир асты байлыкларын өйрәнү, файдалану һәм саклау өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча планнар, чаралар;<br><br>әйләнә-тирә мохитне саклау буенча чаралар үтәлеше турында хисаплар |
| 6 | Муниципаль контроль органының законлы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәү | Әлеге Регламентның 4.7.2 пункты | Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда җир асты байлыклары участокларыннан файдаланучыларны алдагы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча документлар:<br><br>алдагы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр;<br><br>закон бозуларны бетерү буенча боерыклар һәм чаралар планнары;<br><br>законнарны бозуларны бетерү буенча чаралар үтәлеше турында хисаплар |

Административ регламентка
2 нче кушымта

# Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча гамәлләр эзлеклелеге БЛОК-СХЕМАСЫ

